ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.18а, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 18а йорт, Кече Урыссу
авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 4** **12ноября 2022 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ЗRT санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенә керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 9 санлы карары белән расланган» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" 17 санлы карар нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 23 ноябере 18.00 түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Ташкичү авыл җирлеге, Ташкичү авылы, Чишмә ур., 28А, мәдәният йорты бинасында 2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Ташкичү торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенә керүче Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

-Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, транспорт хезмәтләре күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«ӘЙЕ»                                                  «ЮК».

3.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенына әзерлекне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/ кабул ителгән көннән 5 көн эчендә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы                                        Р.К.Вәлиев